**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 16 » март 2022 ел № 2

2022 елга һәм 2023, 2024 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясы 32 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген яңа редакциядә расларга (1кушымта).
2. Әлеге карар 2022 елдан башлап һәм 2023, 2024 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә кулланыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә һәм Тукай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Г.Г.Минакова

Исполнительный комитет Биюрганского сельского поселения
ОГРН 1061682004798
ИНН 1639032304

Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның «16» мартындагы 2 номерлы карарына кушымта

2022 елга һәм 2023, 2024 еллар планы чорына
Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге

Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге

| Керемнәрнең баш администраторы | Бюджет керемнәре | Исеме |
|---|---|---|
| бюджет классификациясе коды | | |

**Тукай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы**

| | | |
|---|---|---|
| 170 | 1 16 01074 01 0000 140 | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7 бүлегендә билгеләнгән муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан ачыкланган милекне саклау өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар |
| 170 | 1 16 01084 01 0000 140 | Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан ачыкланган әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлар |
| 170 | 1 11 05035 10 0000 120 | Авыл җирлекләре идарә органнарының һәм алар төзегән учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) арендага бирүдән кергән керемнәр |
| 170 | 1 14 02052 10 0000 410 | Авыл җирлекләре идарә органнарының һәм алар төзегән учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) арендага бирүдән кергән керемнәр, әлеге мөлкәт буенча төп средстволарны гаәмлгә ашыру өлешендә |

**Тукай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы**

| | | |
|---|---|---|
| 605 | 1 08 04020 01 1000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 605 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 605 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 605 | 1 16 02020 02 0000 140 | Муниципаль хокукый актларны бозган өчен Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар |
| 605 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 605 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларының салым булмаган башка керемнәре |
| 605 | 1 17 14030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары |
| 605 | 2 02 35118 10 0000 150 | Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр |
| 605 | 2 02 35930 10 0000 150 | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 605 | 2 02 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 605 | 2 04 05020 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларга бирелә торган акчалата иганәләрдән керемнәр |
| 605 | 2 07 05020 10 0000 150 | Физик затлар тарафыннан авыл җирлекләре бюджетларыннан акча алучыларга бирелә торган акчадан кергән акчалардан керемнәр |
| 605 | 2 19 60010 10 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган башка субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калдыкларын авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |

| | | |
|---|---|---|
| 605 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотация |
| 605 | 2 02 49999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар |
| 605 | 2 02 40014 10 0000 150 | Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |